


**“Уйлап тап, иҗат ит, һәрбер эштә ян! Сөекле Тукайдан һәрчак үрнәк ал!”**

# “Бу рәсем нинди әсәрдән?”



















# Туган тел!

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән.
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем
.
И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!